

Мансур ХАФИЗОВ, Рифат ИБРАҺИМОВ, Роза ХӘБИБУЛЛИНА, Кәрим ШАКИРОВ, Максуд ЯРУЛЛИН, Сәяр САБЕРОВ, Фазылҗан ГИМРАНОВ


Рифат ИБРАҺИМОВ, Рәүф АБДУЛЛИН, Камил ФӘТКУЛЛИН

Рифат Фатыйхович. Ул 1990 елның 4 маенда шул хакта кулына кәгазь ала һәм үзенең 55 яшьлек юбилее көнне (5 май) хезмәт юлының яңа баскычына баса — татар милли газетасы редакторы вазифасына керешә.

— Ул чакта татар басмасының кирәклеген яклап, «Горьковская правда» газетасында тарих фәннәре кандидаты Әхмәт Аймасов (К.-Пожар), РСФСРның атказанган укытучысы Сәяр Сабиров (Петрякс), крайны өйрәнүче Фазыл Гимранов (Уразавыл), Казан университеты аспиранты Рифат Фаттахов (Актук) һәм Алимҗан Орловның (Камка) материаллары чыкты. Ә булачак газетаның исеменә килгәндә, татар авыллары вәкилләре җыелышында конкурс игълан иткән идек. Зур Рбишчадан Әхәт Чарлагановның, Ыргыдан Әхмәт Закировның һәм Моклокадан Хәсәнә Биляловaның вариантларын конкурс комиссиясе отышлы дип тапты һәм газетабызга «Туган як» исеме бирелде, — ди Рифат абый.

Татар газетасы редакциясе Сергач газетасы редакциясе бинасыннан бүленеп бирелгән бер бүлмәдә оеша башлады. Аның беренче санын октябрь башы белән чыгарырга тиеш идек, хәтта подписка да игълан ителде. Шул вакытта Рифат абый редакциягә яраклы бина һәм автомобиль кайгыртты.

Ләкин, объектив сәбәпләр буенча, газета бераз тоткарланды һәм аның беренче саны 7 декабрьдә генә дөнья күрде. Шул тарихи санның чыгуына караган мәгълүматларга күз ташласак, анда җаваплы секретарь итеп Олег Әндәрҗановны, крайны өйрәнү бүлеге мөдире Әминә Хәсәнованы, әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Рәйсә Каюмованы, хатлар бүлеге мөдире Сафа Мостафинны, корректор Наил Җәфәровны һәм машинистка Нажия Зиһаншинаны танып алырга мөмкин. К.Октябрь, Пильна, Сергач, Спас районнарының халык депутатлары Советлары һәм КПСС райкомнары,

ХӨРМӘТЛЕ РИФАТ ФАТЫЙХОВИЧ, ОЛУГ ЮБИЛЕЕГЫЗ МӨБАРӘК БУЛСЫН, ИҖАДИ КҮҢЕЛЕГЕЗ ИЛҺАМ БЕЛӘН ТУЛСЫН, БАР ЭШЕГЕЗ УҢСЫН, ГАИЛӘ КАПКАГЫЗГА БӘХЕТ КУНСЫН.

Түбән Новгород татар мәдәнияте җәмгыяте оештырган «Туган як» газетасының беренче саны ике мең тираж белән чыкты.

— Сергач типографиясен татар хәрефләре белән тәэмин итүдә аның директоры Николай Ужицын нык булышты. Татарстанда чыгып килгән «Социалистик Татарстан», «Яшь ленинчы» һәм «Татарстан яшьләре» газеталары редакцияләренә рәхмәт, кайберләребез аларда стажировка үтте, ә беренчесеннән редактор урынбасары Сәмигулла Хәйретдинов безне хәтта шефлыкка алды, күп мәртәбә Сергачка килеп, газета эшчәнлегенең бөтен нечкәлекләренә өйрәтте. Исемдә, Казан дәүләт университетының журналистика факультетыннан өч кыз безнең редакциядә практика узды. Алардан да күп нәрсәгә өйрәнеп калдык. Соңыннан шушы уку йортын читтән торып Олег Әндәрҗанов белән Камил Фәткуллин тәмамладылар.

Менә шулай коллектив туплап, тәҗрибә җыеп эшли башлагач, «Евразия» фонды оештырган конкурста грант оттык һәм шуның исәбенә редакциянең нәшер комплексын тулаем компьютерга күчердек. «Туган як» үзенең бишьеллык юбилеен заманча кыяфәттә каршы алды, тиражын 4300 данәгә кадәр күтәрде, 12 битлек булып чыгарга омтылыш ясады. Газета каршында телестудия ачу эшләрен дә кайгырта башлаган идек. Тик минем редакторлык кайберләргә ошап җитмәде һәм шуның белән бергә бу планнар да чәлпәрәмә китте. Ә газетаның бүгенгесе, Аллага шөкер, гел яхшы якка үзгәреп тора, — дип сөйләде «Туган як»ның беренче һәм хөрмәтле редакторы Рифат абый Ибраһимов.

Ул үзенең 80 яшен тутырса да, әзлекле хезмәтен дәвам итә. Хәзер Рифат Фатыйхович «Нижгар татарлары. Биографик сүзлек»нең икенче томын җыеп бетерә инде. Нижгар мишәрләре сүзлеге өстендә дә тыгыз эшли, монысын да китап итеп чыгармакчы. Шул өлкәдә ярдәмне Нижгар татарлары автономиясеннән көтә.

Рифат абыйның шәкерте буларак, остазыма нык сәламәтлек, парлы тыныч картлык, бала-оның шатлыгы телим һәм якын киләчәктә яңа китапларының «Туган як» редакциясе киштәсендә күрәсенә нык ышанасы килә.

Хөрмәтле Рифат Фатыйхович, олуг юбилеегыз мөбарәк булсын, иҗади күңелегез илһам белән тулсын, бар эшегез уңсын, гаилә капкагызга бәхет кунсын.